# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“27” ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 27 ноябрендә «Сез 2020 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Чембулат авылында зиярат коймаларын ремонтлауга төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 94 (туксан дүрт) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 68 (алтмыш сигез) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 68 (алтмыш сигез) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2021 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Чембулат авылында зиярат коймаларын ремонтлау өчен төзү материаллары алу мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулатавылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.